**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 август № 559

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм алар буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген функциональ анализлау методикасын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен тормышка ашыруны тәэмин итү регламентын раслау турында» 2011 ел, 5 март, 178 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм алар буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген функциональ анализлау методикасын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен тормышка ашыруны тәэмин итү регламентын раслау турында» 2011 ел, 5 март, 178 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм алар буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген функциональ анализлау методикасында (алга таба – Методика):

1 бүлекнең беренче абзацында «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карарында билгеләнгән вәкаләтләрен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, алар буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ үткәрү өлешендә гамәлгә ашыру, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 бүлекнең 2.2 нче пунктында:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2012 ел, 21 август, 1199 нчы Указы нигезендә башкарма органның эшчәнлек өлкәләренә караган Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен үтәү (булган очракта);»;

уникенче – унөченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген стимуллаштыру чаралары турында» 2016 ел, 2 июль, 453 нче карары нигезендә структур бүлекчәләргә һәм аларның белгечләренә беркетелгән дәүләт идарәсе функцияләре үтәлешен бәяләү буенча нәтиҗәлелекнең исәпләнә торган төп күрсәткечләре булган очракта;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген стимуллаштыру чаралары турында» 2016 ел, 2 июль, 453 нче карары нигезендә эшләнгән дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан аңа беркетелгән дәүләт идарәсе функцияләрен башкару һәм аларны тормышка ашыруны тасвирлау буенча ведомство стандарты булган очракта;»;

ундүртенче абзац үз көчен югалткан дип санарга;

егерменче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«башкарма орган эшчәнлегенең «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль закон таләпләренә туры килүе һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең сатып алулар планы булган очракта – ведомство буйсынуындагы учреждение эшчәнлегенең «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар турында» 2011 ел, 18 июль, ФЗ-223 нче Федераль закон таләпләренә туры килүе;»;

3 бүлектә:

3.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Ведомство буйсынуындагы учреждениегә функциональ анализ Методикага теркәлгән 3 нче кушымта нигезендә башкарма органның ведомство буйсынуындагы типлаштырылмаган учреждениесе эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү стандарты буенча үткәрелә.»;

3.2.1 нче пунктчага «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

3.2.3 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.3. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2012 ел, 21 август, 1199 нчы Указы нигезендә башкарма органның эшчәнлек өлкәләренә караган Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен үтәү анализы (булган очракта).»;

3.2.6 нчы пунктчаның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«структур бүлекчәләргә һәм аларның белгечләренә беркетелгән дәүләт идарәсе функцияләрен башкару нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен бәяләү методикасы булуын тикшерү.»;

3.2.12 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.12. Башкарма орган эшчәнлегенең «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль закон таләпләренә туры килүен бәяләү һәм ведомство буйсынуындагы учреждение эшчәнлегенең «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар турында» 2011 ел, 18 июль, ФЗ-223 нче Федераль закон таләпләренә туры килүен бәяләү.».»;

Методикага теркәлгән 1 нче кушымтада:

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «4. | Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2012 ел, 21 август, 1199 нчы Указы нигезендә беркетелгән башкарма органның эшчәнлек өлкәләренә караган Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе буенча уртачалардан түбәнрәк булмаска тиеш (булган очракта)»; | |

6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «6. | Башкарма органда беркетелгән дәүләт идарәсе функцияләрен башкару процессларын үтәүнең ведомство стандарты эшләнгән булырга тиеш»; | |

12 нче пунктка «исәпләнә торган» сүзеннән соң «төп эшчәнлек күрсәткечләре» сүзләрен өстәргә;

19 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «19. | Башкарма орган эшчәнлеге «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль закон таләпләренә туры килергә тиеш; | |

20 – 22 нче пунктлар үз көчен югалткан дип санарга;

28 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «28. | Дәүләт хезмәткәрләре саны Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2013 ел, 13 декабрь, ПУ-1215 нче Указы нигезендә башкарма орган өчен билгеләнгән санга туры килергә тиеш; | |

30 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «30. | Башкарма органда эш урыннары урнаштыру өчен бүлмәләр мәйданы нормативлары.<br>Мәгълүмат-коммуникация технологияләренә һәм элемтә хезмәтләренә нормативлар.<br>Программалар белән тәэмин итүне эксплуатацияләүгә һәм челтәр җиһазларына нормативлар.<br>Башкарма органның структур бүлекчәләрен җиһаз, аерым матди-техник ресурслар белән тәэмин итү нормативлары (номенклатура һәм саны).<br>Коммуналь хезмәтләрдән, кәгазь продукциясеннән һәм канцелярия кирәк-яракларыннан, хуҗалык товарларыннан һәм көнкүреш ихтыяҗларындагы товарлардан файдалану нормативлары.<br>Чаралар үткәрүгә нормативлар. | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы дәүләт бюджеттан тыш фондларының идарә органнары һәм аларның ведомство буйсынуындагы оешмалары белән дәүләт идарә итүенең беркетелгән функцияләре кысаларында вәкаләтләрне башкаруга норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләренә туры килергә тиеш.<br>Үтәү (үтәмәү) турында билгеләп куела»; |

34 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «34. | Башкарма органга беркетелгән дәүләт һәм (яки) ведомство максатчан программаларында күрсәтелгән максатлар һәм бурычлар башкарма орган функцияләренә һәм вәкаләтләренә туры килергә тиеш»; | |

35 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «35. | Дәүләт һәм (яки) ведомство максатчан программаларын тормышка ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре үтәлергә тиеш»; | |

Методикага теркәлгән 2 нче кушымтада:
3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «3. | Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2012 ел, 21 август, 1199 нчы Указы нигезендә беркетелгән башкарма органның эшчәнлек өлкәләренә караган Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре үтәлешен анализлау (булган очракта) | үтәлгән / үтәлмәгән дип язып куела»; | |

4 нче һәм 5 нче пунктлар үз көчен югалткан дип санарга;
6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «6. | Башкарма орган турындагы нигезләмәнең Дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторына туры килүен анализлау | туры килә / туры килми / өлешчә туры килә / өстәмә функцияләр (функциональ бурычлар) кертелде дип язып куела»; | |

6 – 9 нчы пунктларда «функциональ бурычлар» сүзләрен «вәкаләтләр» сүзләренә алмаштырырга;
16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «16. | Башкарма орган эшчәнлегенең «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль закон таләпләренә туры килүен бәяләү | туры килә / туры килми / өлешчә туры килә дип язып куела»; | |

35 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «35. | Башкарма орган биләгән мәйданны (бинаның эчке параметры һәм янындагы территория) һәм алар биләгән бинада башка арендаторлар булуын билгеләү.<br>Түбәндәгеләргә туры килүне бәяләү:<br>башкарма органда эш урыннары урнаштыру өчен бүлмәләр мәйданы нормативларына;<br>мәгълүмат-коммуникация технологияләренә һәм элемтә хезмәтләренә нормативларга;<br>программалар белән тәэмин итүне эксплуатацияләүгә һәм челтәр җиһазларына нормативларга;<br>башкарма органның структур бүлекчәләрен җиһаз, аерым матди-техник ресурслар белән тәэмин итү нормативларына (номенклатура һәм саны);<br>коммуналь хезмәтләрдән, кәгазь продукциясеннән һәм канцелярия кирәк- яракларыннан, хуҗалык товарларыннан һәм көнкүреш ихтыяҗларындагы товарлардан файдалану нормативларына;<br>чаралар үткәрүгә нормативларга | мәйданның мәгънәсе күрсәтелә;<br>арендаторлар булу / булмау язып куела»; | |

Әлеге карарга теркәлгән кушымтада китерелгән редакциядә Методикага 3 нче кушымта өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен тормышка ашыруны тәэмин итү регламентында (алга таба – Регламент):

1.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Икътисад министрлыгы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләре эшчәнлегенә функциональ анализ үткәрүне оештыру өчен җаваплы үзәк булып тора. Функциональ анализ «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – ТР ИСТҮ ДБУ) тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының боерыгы белән ел саен раслана торган функциональ анализ үткәрү графигы нигезендә үткәрелә. Аерым очракларда функциональ анализ үткәрүгә бәйсез экспертларны җәлеп итү рөхсәт ителә.»;

1.5 нче пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип санарга;

Регламентка теркәлгән 2 нче кушымтада:

6 нчы пунктка «һәм штаттагы вазыйфаларны биләү[7]» сүзләрен өстәргә;

14 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр булган очракта – түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган белешмә:

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр саны;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең исеме һәм оештыру-хокукый формасы[15];

ведомство буйсынуындагы учреждение уставы;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләрне финанслау чыганаклары[16];

штат расписаниесе һәм штат саны[17];

бюджет (бюджеттан тыш) финанславы күләме[18];

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары.»;

Регламентка теркәлгән 3 нче кушымтада «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» сүзләрен «ТР ИСТҮ ДБУ» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка теркәлгән 4 нче кушымтаның «Күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр» графасында «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» сүзләрен «ТР ИСТҮ ДБУ» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы ачыкламасы (нигезләве)» графасында «(нигезләве)» сүзен төшереп калдырырга;

Регламентка теркәлгән 5 нче кушымта исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« ________________________________________ башкарма органының ___________
(башкарма орган исеме)
_____________________________________ бүлекчәсенә һәм аның хезмәткәрләренә
(бүлекчә исеме)
беркетелгән дәүләт идарәсе функцияләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре турында мәгълүмат»;

Регламентка теркәлгән 6 нче кушымтада:

5 графа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшләрнең үтәлешен раслый торган документның булуы (+) яки булмавы турында билгеләү»;

6 графа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Искәрмә: кирәк булган очракта белгечләр саны һәм аларның эшләрне башкару вакыты турында билгеләп куела».

2. Бу карарның гамәле 2016 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков